Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

28 август 2020 ел №391

Социаль ярдәм чараларын күрсәтү буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтле орган турында

«Татарстан Республикасында муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына социаль ярдәм чараларын күрсәтү буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2020 елның 21 июлендәге 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетын муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны туклануны тәэмин итү өлешендә социаль ярдәм чараларын күрсәтү буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтле орган итеп билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетына социаль ярдәм күрсәтү чараларын күрсәтү буенча Татарстан Республикасының тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җаваплы вазыйфаи затларны билгеләргә.
3. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны район Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов